ОЛЫЯЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

9 июнь 2021 ел № 11

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты, Олыяз авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Советы

К А Р А Р  Б И Р Д Е :

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Олыяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» Олыяз авыл җирлеге Советының 2014 елның 30 гыйнварындагы 3 номерлы карары (2016 елның 16 декабрендәге 39 номерлы, 2018 елның 21 июнендәге 20 номерлы, 2019 елның 20 февралендәге 3 номерлы, 2019 елның 29 августындагы 19 номерлы Олыяз авыл җирлеге Советы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Олыяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең «Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә», 18.1 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

«18. 1. Җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре:

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлекләренең минималь күләме – 1 000 кв.м.

«Шәхси торак төзелеше» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлегенең максималь күләме – 2500 кв.м, «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» – 5000 кв.м.»

2. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Олыяз авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Маликов

ОГРН 1021607754651
ИНН 1623001879